169. «И.Ш. Низамиевны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ..............................................................193

170. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының $1.1^1$ һәм 8.2 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 83-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының вазыйфаи затлары исемлеген билгеләү турында) алдан карау хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе*.....................................194

171. «Р.М. Мифтаховны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ..............................................................195

172. «С.В. Андреевны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында»

*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................195

173. «Ф.В. Вәлиевне Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................196

174. «М.Ф. Ванееваны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................196

175. «З.Г. Гыймрановны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................197

176. «Г.Ә. Сираҗиеваны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................197

177. «Г.Г. Фазылованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................198

178. «Р.М. Мөхәммәтшинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................198

179. «З.Д. Сөнгатуллинаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................199

180. «Р.М. Гариповаңы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................199



181. «Д.В. Пивоваровны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................200

182. «Э.Н. Крупинаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................200

183. «В.А. Демагинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................201

184. «Г.Н. Корсаковаңы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................201

185. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 82-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган мәгариф оешмаларында укучыларга һәм аларны тәмамлаучыларга уку-укыту программасының дәүләт аккредитациясенә бәйсез рәвештә социаль ярдәм чараларын тарату өлешендә) алдан карау турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................202

186. «Г.Н. Закироваңы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................203

187. «Х.Х. Хәмидуллинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................ 203

188. «М.Р. Сафинаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................ 204

189. «А.А. Ивановны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................ 204

190. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 12 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 85-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары вәкаләтләрен төгәлләштерү өлешендә) алдан карау хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ................................................ 205

191. «Г.З. Гарифовны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................ 206

192. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.В. Прокофьев, Х.Г. Миргалимов, А.В. Комисаров тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында Җиңү Байрагы күчермәсен куллану турында» 84-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* .......................... 206



193. «Р.Г. Фәттаховны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................ 207

194. «Ю.Г. Якимованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................ 207

195. «Р.Х. Храмченкованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................ 208

196. «Ю.И. Фатыйховны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................ 209

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1. «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
2014 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2001, № 12; 2004, № 2 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 3; 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 8; 2013, № 7; 2014, № 6 (II өлеш), № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Гыйбадәт кылулар, башка дини йолалар һәм тантаналар түбәндәгеләрдә тоткарлыксыз башкарыла:
гыйбадәт урыннарында, биналарында һәм корылмаларында, шулай ук мондый биналар һәм корылмалар урнашкан җир кишәрлекләрендә;
дини оешмаларның милек хокукындагы яисә аларның устав эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен аларга башка мөлкәт хокукында бирелгән биналарда һәм корылмаларда, шулай ук мондый биналар һәм корылмалар урнашкан җир кишәрлекләрендә;
дини оешмаларның милек хокукындагы яисә аларның устав эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен аларга башка мөлкәт хокукында бирелгән урыннарда, шулай ук, тиешле урыннары булган биналарның милекчеләре белән килештереп, мондый биналар урнашкан җир кишәрлекләрендә;
дини оешмалар төзегән оешмаларның милек хокукындагы яисә аларга башка мөлкәт хокукында бирелгән урыннарда, биналарда, корылмаларда һәм җир кишәрлекләрендә;
дини оешмаларның милек хокукындагы яисә аларга башка мөлкәт хокукында бирелгән җир кишәрлекләрендә;



гыйбадәт кылу урыннарында;
зиратларда һәм крематорийларда;
торак урыннарда.»;

2) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«5. Башка очракларда җәмәгать урыннарында җәмәгать тәртибен һәм дини йолаларда һәм тантаналарда катнашучыларның да, башка гражданнарның да иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны таләп итә торган шартларда үткәрелә торган гавами гыйбадәт кылулар, башка дини йолалар һәм тантаналар (гыйбадәт кылу җыелышларын һәм дини җыелышларны кертеп) митинглар, урам йөрешләре һәм демонстрацияләр уздыру өчен билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 16 гыйнвары
№ 1-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 2. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 5; Ватаным Татарстан, 2014, 21 ноябрь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяда:

а) 3 пунктта «һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексының $97^1$ статьясы нигезендә депутат мандаты тапшырылган кандидатларның республика исемлеге составында сайланган һәр депутатка» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) $3^1$ пунктның беренче абзацында «шулай ук Татарстан Республикасы Сайлау кодексының $97^1$ статьясы нигезендә депутат мандаты тапшырылган кандидатларның республика исемлеге составында сайланган» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 7 статьяның 3 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

3) $7^1$ статьяда:

а) 2 пунктта «Татарстан Республикасы Сайлау кодексының $97^1$ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатларның республика исемлекләре составында сайланган депутатлар,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 7 пунктның икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

4) $10^1$ статьяда:

а) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:



«2. Депутатның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр Россия Федерациясе Президенты раслаган белешмә формасы буенча тапшырыла.»;

б) 5 пунктның икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Депутат әлеге статьяның 1 пункты нигезендә белешмәләр тапшырган көннән алып бер ай эчендә төгәлләштерелгән белешмәләрне тапшыра ала.»;

5) 1 нче һәм 2 нче кушымталарны үз көчләрен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 16 гыйнвары
№ 2-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 3. Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 24 декабрендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның гамәлдә булу даирәсе**

1. Әлеге Закон «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татар-

стан Республикасы законнары нигезендә төзелә торган бүтән дәүләт органнары (алга таба — дәүләт органнары), Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары (алга таба — җирле үзидарә органнары) эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала.

2. Әлеге Законның гамәлдә булу көче мәгълүматтан файдаланучыларның дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле мөнәсәбәтләргә кагыла.

2 статья. **Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү рәвеше**

1. Дәүләт органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат телдән һәм документлаштырылган мәгълүмат рәвешендә, шул исәптән электрон документ рәвешендә бирелергә мөмкин.

2. Дәүләт органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат, әгәр аларның эшчәнлеге турында мәгълүмат бирүнең бүтән ысулы гаризада күрсәтелмәгән булса, мәгълүматтан файдаланучының язма гаризасына җавап итеп, язма рәвештә бирелә.

3. Дәүләт органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүмат, әгәр ул соралган рәвешендә бирелә алмаса, мәгълүматның нинди рәвештә булуыннан чыгып бирелә. Мәгълүматтан файдаланучыга мәгълүматны соралган рәвешендә бирү мөмкинлеге булмау турында хәбәр ителергә тиеш, хәбәрдә мәгълүматның мәгълүматтан файдаланучы тарафыннан күрсәтелгән рәвештә бирелә алмавының сәбәбе күрсәтелергә тиеш.

4. Мәгълүматтан файдаланучыларга дәүләт органнары эшчәнлеге турында телдән мәгълүмат аларны кабул итү вакытында бирелә. Әлеге мәгълүмат шулай ук дәүләт органының белешмә бирү хезмәтләре телефоннары аша йә дәүләт органының мәгълүмат бирергә вәкаләтле вазыйфаи затлары телефоннары аша бирелә.

5. Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү рәвеше федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында билгеләнә, шулай ук муниципаль хокукый актларда билгеләнергә мөмкин.

6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат гомуми файдаланудагы элемтә челтәрләре аша тапшырылырга мөмкин.



3 статья. **Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат биргәндә дәүләт телләрен куллану**

1. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә бирелә.

2. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат соралган гаризаны язганда һәм гаризага җавап биргәндә Татарстан Республикасы дәүләт телләре кулланыла.

4 статья. **Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген оештыру**

1. Дәүләт органы, җирле үзидарә органы эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеге дәүләт органының, җирле үзидарә органының тиешле структур бүлекчәсе яисә вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан тәэмин ителә.

2. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген оештыру, Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән тәртиптә үз вәкаләтләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә гомуми файдаланудагы мәгълүмат системаларына, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә, шулай ук күрсәтелгән органнар урнашкан биналарда һәм шушы максатлар өчен бүлеп бирелгән урыннарда урнаштырыла.

4. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында китапханә һәм архив фондларында саклана торган мәгълүмат белән мәгълүматтан файдаланучыларны таныштыру китапханә һәм архив эше турындагы Россия Федерациясе законнарында һәм алар нигезендә кабул ителгән бүтән норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә, шулай ук китапханә һәм архив эше турындагы Татарстан Республикасы законнарында һәм дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының алар нигезендә кабул ителгән бүтән норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

5 статья. **Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә урнаштырыла торган мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген оештыру**

1. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары үз эшчәнлекләре турында мәгълүмат урнаштыру өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланалар, анда, гариза юллана алган электрон почта адресын күрсәтеп, үзләренең рәсми сайтларын булдыралар. Җирле үзидарә органының үз эшчәнлеге турында мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә урнаштыру мөмкинлеге булмаган очракта, күрсәтелгән мәгълүмат Татарстан Республикасының рәсми сайтына (порталына) урнаштырылырга мөмкин. Муниципаль районга керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат шул муниципаль районның рәсми сайтына урнаштырылырга мөмкин.

2. Дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларына мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

3. Дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының рәсми сайтларыннан файдалануны тәэмин итүнең технологик, программа һәм лингвистик чараларына карата таләпләр күрсәтелгән органнар тарафыннан үз вәкаләтләре чикләрендә билгеләнә.

6 статья. **Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә урнаштырыла торган мәгълүмат исемлекләре**

1. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан урнаштырыла торган һәркем файдалана алырлык мәгълүматның, шул исәптән ачык белешмәләр рәвешендә урнаштырыла торган мәгълүматның составы (Федераль законның 14 статьясындагы 71 өлешендә күрсәтелгән мәгълүматтан тыш) шул органнар эшчәнлеге турындагы мәгълүматның тиешле исемлекләре белән билгеләнә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшчәнлеге турында мәгълүмат исемлеге Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә раслана.



3. Татарстан Республикасы Президенты эшчәнлеге турында мәгълүмат исемлеге Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

5. Бүтән дәүләт органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат исемлекләре шул дәүләт органнары тарафыннан раслана.

6. Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат исемлекләре җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә раслана.

7 статья. **Әлеге Законның үз көченә керү тәртибе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 16 гыйнвары
№ 3-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 4. Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 24 декабрендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

1. Әлеге Закон «Җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында» 2014 елның 2 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә кабул ителде һәм Татарстан Республикасы территориясендә җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуын оештыруга бәйле мәсьәләләрне җайга сала.

2. Әлеге Закон халык дружиначысы таныклыгы үрнәген һәм аны бирү тәртибен, халык дружиначысының махсус символикасы үрнәген, халык дружиналарының координацияләү органнарын (штабларын) төзү һәм аларның эшчәнлеге тәртибен билгели.

2 статья. **Төп терминнар һәм төшенчәләр**

Әлеге Законда төп терминнар һәм төшенчәләр Федераль закондагы мәгънәләрендә кулланыла.

3 статья. **Җәмәгать тәртибен саклауда гражданнар катнашуының хокукый нигезе**

Җәмәгать тәртибен саклауда гражданнар катнашуының хокукый нигезен Россия Федерациясе Конституциясе, халыкара хокукның гомумтанылган принциплары һәм нормалары, федераль конституциячел законнар, Федераль закон, башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының бүтән норматив хокукый актлары, муниципаль норматив хокукый актлар тәшкил итә.

4 статья. **Җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуын җайга салу өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

1. Җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуын җайга салу өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты түбәндәге вәкаләтләрне башкара:

1) җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуын җайга салу өлкәсендә норматив хокукый актлар кабул итә;

2) җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә ярдәм итә;

3) Татарстан Республикасында халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча республика штабын төзи;

4) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында хәбәрсез югалган затлар, аларны эзләүнең якынча урыны турында гомуми файдалана алырлык мәгълүмат, хәбәрсез югалган затларны эзләү чаралары координаторларының контакт мәгълүматлары, хәбәрсез югалган затларны нәтиҗәле эзләү өчен кирәкле башка гомуми файдалана алырлык мәгълүмат урнаштыра;

5) җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә мәгълүмати-методик ярдәм күрсәтә;

6) җәмәгать тәртибен саклау буенча эчке эшләр органнары (полиция) яисә башка хокук саклау органнары тарафыннан уздырыла торган чараларда катнашу чорына халык дружиначыларын шәхси иминләштерүне гамәлгә ашыра;

7) җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуын җайга салу өлкәсендә федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне башкара.

2. Әлеге статьяда билгеләнгән вәкаләтләрне башкару тәртибе законнар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

5 статья. **Җәмәгать тәртибен саклауда гражданнар катнашуын җайга салу өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә Федераль законда, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда, башка федераль законнарда, әлеге Законда һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән вәкаләтләр нигезендә ярдәм итә, халык дружиналарының эшчәнлеге өчен шартлар тудыра.

2. Хәбәрсез югалган затларны эзләүдә катнашучы гражданнарга булышу максатларында җирле үзидарә органнары «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзләренең рәсми сайтларында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында хәбәрсез югалган затлар, аларны эзләүнең якынча урыны турында гомуми файдалана алырлык мәгълүмат, хәбәрсез югалган затларны эзләү чаралары координаторларының контакт мәгълүматлары, хәбәрсез югалган затларны нәтиҗәле эзләү өчен кирәкле башка гомуми файдалана алырлык мәгълүмат урнаштыра.

Мондый мәгълүматны урнаштыру тәртибе муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

3. Җирле үзидарә органнары, хәбәрсез югалган затларны эзләүдә оештырылган төркемнәр төзү, эзләүнең якынча маршрутын һәм урынын билгеләү мәсьәләләрен, башка мәсьәләләрне хәл итү өчен, хәбәрсез югалган затларны эзләүдә катнашучы

гражданнарга җирле үзидарә органнарының тәкъдимнәрен юллау тәртибен билгели.

4. Татарстан Республикасында тиешле муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары халык дружинасы төзелергә мөмкин булган территориянең чикләрен билгели.

5. Җирле үзидарә органнары халык дружиналары эшчәнлеген матди-техник тәэмин итүне финанслауга акча бүлеп бирергә, халык дружиналарына биналар, аларның эшчәнлеген башкару өчен кирәкле техник һәм башка матди чаралар бирергә мөмкин.

6. Җирле үзидарә органнары тиешле бюджетлар акчалары исәбеннән халык дружиначыларының эшчәнлеген матди кызыксындырырга, халык дружиначыларына муниципаль берәмлек территориясе чикләрендә шәһәр, шәһәр яны һәм җирле җәмәгать транспортының барлык төрләре өчен (таксидан тыш) йөрү билетлары бирергә, халык дружиначыларына һәм аларның гаилә әгъзаларына өстәмә ташламалар һәм компенсацияләр, хокукый һәм социаль яклау гарантияләрен билгеләргә, шулай ук матди кызыксындыруның Россия Федерациясе законнарына һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган башка рәвешләрен кулланырга мөмкин.

Җирле үзидарә органнары тарафыннан халык дружиначыларына ташламалар һәм компенсацияләр бирү тәртибе муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

### 6 статья. **Халык дружиналарын координацияләү органнары (штаблар)**

1. Татарстан Республикасы территориясендә халык дружиналарының эшчәнлеген координацияләүне һәм аларның Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук эчке эшләр органнары (полиция) һәм башка хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлеген гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасында халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча республика штабы (алга таба – Республика штабы) төзелә.

2. Республика штабы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан төзелә һәм даими эшләүче коллегиаль орган булып тора. Республика штабының структурасын һәм составын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслый.

3. Республика штабының төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:



1) халык дружиналары эшчәнлеген җәмәгать тәртибен саклауда эчке эшләр органнарына (полициягә) һәм башка хокук саклау органнарына ярдәм итү мәсьәләләре буенча координацияләү;

2) халык дружиналары эшчәнлеге турында мәгълүматны гомумиләштерү һәм анализлау һәм Татарстан Республикасында халык дружиналары командирлары өчен өйрәтү семинарлары уздыру;

3) эчке эшләр органнарына (полициягә) һәм башка хокук саклау органнарына җәмәгать тәртибен саклауда ярдәм итү мәсьәләләре буенча халык дружиналары өчен тәкъдимнәр эшләү;

4) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән башка бурычлар.

4. Төп бурычларны үтәү максатларында Республика штабы түбәндәге функцияләрне башкара:

1) халык дружиналары эшчәнлеген координацияләүгә һәм эчке эшләр органнарына (полициягә) һәм башка хокук саклау органнарына җәмәгать тәртибен саклауда ярдәм итүгә бәйле мәсьәләләрне һәм тәкъдимнәрне карау;

2) үз компетенциясе чикләрендә карарлар кабул итү;

3) халык дружиналары командирларына, аларның урынбасарларына таныклыклар ясау, тапшыру һәм ул таныклыкларны алмаштыру;

4) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән башка функцияләр.

5. Тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә халык дружиналарының үзара хезмәттәшлеге һәм аларның эшчәнлеген координацияләү максатларында җирле үзидарә органнары халык дружиналарын координацияләү органнары (штаблар) төзергә мөмкин.

6. Халык дружиналарын координацияләү органнарын (штабларны) төзү һәм аларның эшчәнлеге тәртибе әлеге Законга 1 нче кушымтада билгеләнә.

### 7 статья. **Халык дружиначысының таныклыгы һәм махсус символикасы**

1. Халык дружиначысы җәмәгать тәртибен саклауда катнашканда әлеге Законга 2 нче һәм 4 нче кушымталар нигезендә форма киеме һәм (яисә) кул повязкасы рәвешендә халык дружиначысының махсус символикасын кулланырга һәм билгеләнгән үрнәктә ясалган халык дружиначысы таныклыгын үзендә йөртергә тиеш.

2. Халык дружиначысы таныклыгын бирү тәртибе әлеге Законга 3 нче кушымтада билгеләнә.

3. Халык дружиначысының форма киеме җәмәгать тәртибен саклау чараларында катнашканда халык дружиначысы киеп йөрү өчен каралган өс киеменең күренеп тора торган бертөрле тышкы билгеләр булган элементыннан гыйбарәт.

4. Халык дружиначысына форма киеме һәм (яисә) кул повязкасы дежурлыкка керешкәндә халык дружинасы командиры тарафыннан бирелә.

5. Халык дружинасында әгъза булуны туктатканда яисә таныклыкның гамәлдә булу вакыты чыккан очракта таныклык халык дружинасы командирына тапшырылырга тиеш.

6. Халык дружиначысы таныклыгы, форма киеме һәм кул повязкасы халык дружиналары акчалары исәбеннән әзерләнә.

8 статья. **Халык дружиначыларын матди кызыксындыру һәм шәхси иминләштерү**

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән халык дружиначылары эшчәнлеген матди кызыксындыруны гамәлгә ашырырга мөмкин.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты җәмәгать тәртибен саклау буенча эчке эшләр органнары (полиция) яисә башка хокук саклау органнары тарафыннан уздырыла торган чараларда катнашу чорына халык дружиначыларын шәхси иминләштерүне гамәлгә ашыра.

3. Иминият суммалары халык дружиначысы җәмәгать тәртибен саклау буенча эчке эшләр органнары (полиция) яисә башка хокук саклау органнары тарафыннан уздырыла торган чараларда катнашу чорында түбәндәге иминият очраклары барлыкка килгәндә түләнә:

1) халык дружиначысы һәлак булса;
2) халык дружиначысына инвалидлык билгеләнсә;
3) халык дружиначысы тән җәрәхәтләре алса.

9 статья. **Җәмәгать тәртибен саклауны гамәлгә ашыруда катнашучы гражданнарны дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан бүләкләү чаралары**

1. Җәмәгать тәртибен саклауда һәм хокук бозуларга каршы көрәштә актив катнашкан өчен халык дружиначылары Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан түбәндәгечә бүләкләнергә мөмкин:

1) рәхмәт белдерү;



2) акчалата премия бирү;
3) кыйммәтле бүләк тапшыру;
4) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының мактау грамоталары, җирле үзидарә органнарының мактау грамоталары белән бүләкләү.

2. Җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнар иҗтимагый бурычларын үтәгәндәге аерым казанышлары, шул чакта күрсәткән батырлыклары һәм каһарманлыклары өчен законнар нигезендә Россия Федерациясе дәүләт бүләкләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренә тәкъдим ителергә мөмкин.

3. Бүләкләүләр Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешле бюджетлар акчаларыннан, физик һәм юридик затларның ихтыярый иганәләреннән һәм законнарда тыелмаган башка чыганаклардан бирелә.

10 статья. **Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану**

Әлеге Закон үз көченә кергән көннән түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә гражданнарның катнашуы турында» 2005 елның 1 ноябрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын;

2) «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә гражданнарның катнашуы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын;

3) «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә гражданнарның катнашуы турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 23 июнендәге 25-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын;

4) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 12 июнендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясын.

11 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенең норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә, шулай ук әлеге Закон үз көченә кергән көннән алып алты ай эчендә аны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 16 гыйнвары
№ 4-ТРЗ

«Татарстан Республикасында
җәмәгать тәртибен саклауда
гражданнарның катнашуы турында»
Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

**Халык дружиналарын координацияләү органнарын (штабларны) төзү һәм аларның эшчәнлеге тәртибе**

1. Федераль законның 13 статьясы нигезендә әлеге Тәртип халык дружиналарын координацияләү органнарын (штабларны) төзү һәм аларның эшчәнлеге тәртибен билгели.

2. Халык дружиналарын координацияләү органнары (штаблар) халык дружиналарының үзара хезмәттәшлеге һәм аларның эшчәнлеген координацияләү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан төзелергә мөмкин.

3. Халык дружиналарын координацияләү органын (штабны) төзү турында карар, аның составын раслау бу органны төзү турында карар кабул иткән органның хокукый акты белән рәсмиләштерелә.

4. Халык дружиналарын координацияләү органы (штаб) үз эшчәнлеген аны төзү турында карар кабул иткән орган раслый торган нигезләмә буенча башкара.

5. Халык дружиналарын координацияләү органы (штаб) составына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, башкарма хакимиятнең эчке эшләр өлкәсендәге федераль органының территориаль органы вәкилләре, шулай ук хокук саклау юнәлешендәге иҗтимагый берләшмәләр җитәкчеләре һәм халык дружиналары командирлары кертелергә мөмкин. Халык дружиналарын координацияләү органы (штаб) составына кирәк булганда башка затлар да кертелә ала.



6. Халык дружиналарын координацияләү органын (штабны) халык дружиналарын координацияләү органы җитәкчесе (штаб башлыгы) җитәкли, ул халык дружиналарын координацияләү органын (штабны) төзү турында карар кабул иткән органның вазыйфаи затлары арасыннан билгеләп куела.

7. Халык дружиналарын координацияләү органы (штаб) түбәндәгеләрне башкара:

а) халык дружиналарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм хокук саклау органнары белән җәмәгать тәртибен саклау мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлеген оештыра;

б) халык дружиналары эшчәнлегенең төп мәсьәләләрен карый, халык дружиначылары эше вакытында килеп чыга торган мәсьәләләрне ачыклый, аларны хәл итү өчен тәкъдимнәр эшли;

в) үз эшенә кызыксынучы органнар һәм оешмалар вәкилләрен, башка белгечләрне җәлеп итә;

г) законнар нигезендә башка вәкаләтләр башкара.

«Татарстан Республикасында
җәмәгать тәртибен саклауда
гражданнарның катнашуы турында»
Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

**Халык дружиначысы таныклыгы тасвирламасы һәм үрнәге**

1. Халык дружиначысы таныклыгы 65 х 200 мм үлчәмдәге (ачык килеш) китапчыктан гыйбарәт. Таныклыкның тышы кызыл төстәге материалдан ясала.Таныклыкның эчке ягына ак төстәге кәгазь ябыштырыла.

2. Таныклык тышының уң ягында өске өлештә алтынсу төстәге баш хәрефләр белән ике юлга

«ХАЛЫК ДРУЖИНАЧЫСЫ
ТАНЫКЛЫГЫ» дип языла,

астарак алтынсу төстә горизонталь линия сызыла.

Күрсәтелгән горизонталь линия астына алтынсу төстәге баш хәрефләр белән ике юлга

«УДОСТОВЕРЕНИЕ
НАРОДНОГО ДРУЖИННИКА» дип языла.

3. Таныклыкның эчке ягында сул якта:

өстә бер горизонталь линия, аның астына «(халык дружинасының исеме)» сүзләре языла;

алар астында уртада — «ХАЛЫК ДРУЖИНАСЫ» сүзләре языла;

алар астында уртада — «Таныклык № ____» сүзләре языла;

аскарак өч юлга «Фамилиясе», «Исеме», «Атасының исеме» сүзләре языла, һәрбер юл янәшәсендә уң якка горизонталь сызык сызыла;

күрсәтелгән сүзләрдән аста бер горизонтальдә ике линия сызыла, сулдагысы астына — «(вазыйфасы)», уңдагысы астына «(имза»)  сүзе языла;

астагы өлештә ике юлга түбәндәге сүзләр языла:

«20 ____ елның _______ кадәр гамәлдә

«20 ____ елның _______ кадәр озайтылды».

4. Таныклыкның эчке ягында уң якта:

өстә уртада — «НАРОДНАЯ ДРУЖИНА» сүзләре;

алар астында — бер горизонталь линия сызыла, аның астына «(халык дружинасы исеме)» сүзләре языла;

алар астында уртада — «Удостоверение № ____» сүзләре языла;

күрсәтелгән сүзләрдән аста 2,5 х 3 см зурлыкта фоторәсем (анфас) ябыштырыла;

фоторәсемнән уңда өч юлга «Фамилия», «Имя», «Отчество» сүзләре языла, һәрбер сүз янәшәсендә уң якка горизонталь сызык сызыла;

күрсәтелгән сүзләрдән аста бер горизонтальдә ике линия сызыла, сулдагысы астына — «(должность)», уңдагысы астына «(подпись»)  сүзе языла;

фоторәсем астында мөһер өчен урын калдырыла һәм «М.П.» баш хәрефләре куела;

астагы өлештә ике юлга түбәндәге сүзләр языла:

«Действительно до ______20 ____ года

Продлено до ________20 ____ года».

5. Кирәкле барлык реквизитларны тутырганнан соң таныклык җирле үзидарә органы мөһере белән таныклана: мөһер фоторәсемнең астагы сул почмагы һәм халык дружинасы командиры имзасы куелган юл өстенә сугыла.

6. Халык дружинасы таныклыгы үрнәге






**Эчке якның сул өлеше** | **Эчке якның уң өлеше**

| | |
|---|---|
| ____________ (халык дружинасының исеме) | НАРОДНАЯ ДРУЖИНА |
| ХАЛЫК ДРУЖИНАСЫ | ____________ (наименование народной дружины) |
| Таныклык № ____ | Удостоверение № _____ |
| Фамилиясе ________ | место для фотографии — Фамилия ________ |
| Исеме ________ | Имя ________ |
| Атасының исеме ________ | Отчество ________ |
| ________ (вазыйфасы) ________ (имза) | М.П. ________ (должность) ________ (подпись) |
| 20 ____ елның ________ кадәр гамәлдә | Действительно до ________ 20 ____ года |
| 20 ____ елның ________ кадәр озайтылды | Продлено до ________ 20 ____ года |

«Татарстан Республикасында
җәмәгать тәртибен саклауда
гражданнарның катнашуы турында»
Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта

**Халык дружиначысы таныклыгын бирү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Федераль законның 16 статьясы нигезендә халык дружиначысы таныклыгын бирү тәртибен билгели.

2. Халык дружиначысы таныклыгын рәсмиләштерү «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында» Татарстан Республикасы Законы белән расланган бердәй үрнәк буенча җирлекләрнең, шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан башкарыла.

3. Халык дружиначысы таныклыгы, гражданның язмача гаризасына нигезләнеп, өч елга бирелә.

Таныклыкның гамәлдә булу вакыты өч елга озайтыла.

4. Халык дружиначысы таныклыгы җирле үзидарә органының вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан имзалана һәм җирле үзидарә органы мөһере белән таныклана.

5. Халык дружиначысы таныклыгы халык дружиначысына, аның имзасын алып, кагыйдә буларак, тантаналы рәвештә һәм халык дружинасы әгъзалары катнашында тапшырыла.

6. Җирле үзидарә органы бирелгән таныклыкларның исәбен халык дружиначылары таныклыкларын теркәү журналында алып бара.

7. Халык дружиначысы таныклыгы югалган яисә бозылган, аның гамәлдә булу срогы тәмамланган яисә халык дружиначысының персональ мәгълүматлары үзгәргән очракта таныклык алмаштырыла. Мондый очракта элек бирелгән таныклык (югалган очраклардан тыш) халык дружинасы командиры тарафыннан тиешле җирле үзидарә органына тапшырыла.

8. Халык дружиначысын халык дружинасыннан чыгарган очракта халык дружиначысы таныклыгы халык дружинасы командиры тарафыннан тиешле җирле үзидарә органына кире тапшырыла.

«Татарстан Республикасында<br>җәмәгать тәртибен саклауда<br>гражданнарның катнашуы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>4 нче кушымта

**Халык дружиначысының махсус символикасы тасвирламасы һәм үрнәге**

1. Халык дружиначысының форма киеме яктылыкны кире кайтаргыч өлешләр тегелгән зәңгәр төстәге жилеттан гыйбарәт, аңа түбәндәге язулар төшерелгән:

1) алда уң якта күкрәк кесәсе тигезлегендә — 10 мм зурлыктагы баш хәрефләр белән «НАРОДНАЯ ДРУЖИНА» сүзләре;

2) алда сул якта күкрәк кесәсе тигезлегендә — 10 мм зурлыктагы баш хәрефләр белән «ХАЛЫК ДРУЖИНАСЫ» сүзләре;

3) артта — 60 мм зурлыктагы баш хәрефләр белән «НАРОДНАЯ ДРУЖИНА» сүзләре;

алар астында горизонталь линия;

горизонталь линия астында — 60 мм зурлыктагы баш хәрефләр белән «ХАЛЫК ДРУЖИНАСЫ» сүзләре.

Хәрефләр ак төстәге термосыул белән төшерелә.

2. Халык дружиначысының форма киеменең үрнәге



**Алгы як** **Арткы як**




3. Халык дружиначысының кул повязкасы кызыл төстәге тукымадан тегелгән 250 х 100 мм зурлыктагы турыпочмаклыктан гыйбарәт, аның уртасына 25 — 40 мм зурлыктагы ак төстәге баш хәрефләр белән «ДРУЖИННИК» дип язылa, аның астында горизонталь линия сызыла, линия астына уртага 25 — 40 мм зурлыктагы ак төстәге баш хәрефләр белән «ДРУЖИНАЧЫ» дип языла, язуның озынлыгы 150 — 200 мм тәшкил итә, бәйләп кую өчен каралган өлешләре була.

4. Халык дружиначысының кул повязкасының үрнәге



## 5. «Татарстан Республикасында милли-мәдәни автономияләр турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында милли-мәдәни автономияләр турында» 2003 елның 12 маендагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 5; 2005, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның беренче өлешендә «хәл итү» сүзләреннән соң «, Россия милләте бердәмлеген ныгыту, этникара мөнәсәбәтләрне камилләштерү, диннәр арасындагы диалогка ярдәм итү, шулай ук мигрантларны социаль һәм мәдәни җайлаштыруга һәм интеграцияләүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыру» сүзләрен өстәргә;

2) 4 статьяның беренче өлешендәге 1 пунктында «үстерү» сүзеннән соң «, Россия милләте бердәмлеген ныгыту, этникара мөнәсәбәтләрне камилләштерү, диннәр арасындагы диалогка ярдәм итү, шулай ук мигрантларны социаль һәм мәдәни җайлаштыруга һәм интеграцияләүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыру» сүзләрен өстәргә.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 16 гыйнвары
№ 5-ТРЗ



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 6. «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2014 елның 27 ноябрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 11 (V өлеш), № 11 (VI өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда:
а) 4 өлешнең икенче абзацында «113 996 347,7» саннарын «122 871 347,7» саннарына алмаштырырга;
б) түбәндәге эчтәлекле 7 өлеш өстәргә:
«7. 2015 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «Элемтәинвестнефтехим» ачык акционер җәмгыятенең иярчен компаниясе булып торучы «СИНЕК Кэпитал С.А.» компаниясе тарафыннан 2005 елда җәлеп ителгән заем буенча йөкләмәне тәэмин итү өчен бирелгән Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе буенча Татарстан Республикасы йөкләмәләре күләмен 21 875 000 мең сумга кадәр арттыру максатларында 2005 елның 3 августындагы Гарантия шартнамәсенә өстәмә килешү төзү турында карар кабул итәргә хокуклы.»;

2) 1 нче кушымтаның 1 нче таблицасында:
а)

| | | |
|---|---|---|
| «01 05 00 00 00 0000 500 | Бюджетларның калган чараларын арттыру | -297 953 586,9 |
| 01 05 02 00 00 0000 500 | Бюджетларның калган башка чаралары н арттыру | -297 953 586,9 |
| 01 05 02 01 00 0000 510 | Бюджетларның калган башка акчалары н арттыру | -297 953 586,9 |
| 01 05 02 01 02 0000 510 | Татарстан Республикасы бюджетының калган башка акчаларын арттыру | -297 953 586,9 |

| | | |
|---|---|---|
| 01 05 00 00 00 0000 600 | Бюджетларның калган чараларын киметү | 298 320 355,6 |
| 01 05 02 00 00 0000 600 | Бюджетларның калган башка чаралары киметү | 298 320 355,6 |
| 01 05 02 01 00 0000 610 | Бюджетларның калган башка акчаларын киметү | 298 320 355,6 |
| 01 05 02 01 02 0000 610 | Татарстан Республикасы бюджетының калган башка акчаларын киметү | 298 320 355,6» |

юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «01 05 00 00 00 0000 500 | Бюджетларның калган чараларын арттыру | -306 828 586,9 |
| 01 05 02 00 00 0000 500 | Бюджетларның калган башка чаралары арттыру | -306 828 586,9 |
| 01 05 02 01 00 0000 510 | Бюджетларның калган башка акчаларын арттыру | -306 828 586,9 |
| 01 05 02 01 02 0000 510 | Татарстан Республикасы бюджетының калган башка акчаларын арттыру | -306 828 586,9 |
| 01 05 00 00 00 0000 600 | Бюджетларның калган чараларын киметү | 307 195 355,6 |
| 01 05 02 00 00 0000 600 | Бюджетларның калган башка чаралары киметү | 307 195 355,6 |
| 01 05 02 01 00 0000 610 | Бюджетларның калган башка акчаларын киметү | 307 195 355,6 |
| 01 05 02 01 02 0000 610 | Татарстан Республикасы бюджетының калган башка акчаларын киметү | 307 195 355,6»; |

б)

| | | |
|---|---|---|
| «01 06 04 00 00 0000 000 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне үтәү | -20 265 720,0 |
| 01 06 04 01 00 0000 000 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне Россия Федерациясе валютасында үтәү | -13 000 000,0 |
| 01 06 04 01 00 0000 800 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән йә бенефициарның принципалга карата таләбе хокуклары гарантка биреп торылган очракта, дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне Россия Федерациясе валютасында үтәү | -13 000 000,0 |
| 01 06 04 01 02 0000 810 | Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән йә бенефициарның принципалга карата таләбе хокуклары гарантка биреп торылган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен Россия Федерациясе валютасында үтәү | -13 000 000,0» |

юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «01 06 04 00 00 0000 000 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне үтәү | -29 140 720,0 |
| 01 06 04 01 00 0000 000 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне Россия Федерациясе валютасында үтәү | -21 875 000,0 |
| 01 06 04 01 00 0000 800 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән йә бенефициарның принципалга карата таләбе хокуклары гарантка биреп торылган очракта, дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне Россия Федерациясе валютасында үтәү | -21 875 000,0 |
| 01 06 04 01 02 0000 810 | Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән йә бенефициарның принципалга карата таләбе хокуклары гарантка биреп торылган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен Россия Федерациясе валютасында үтәү | -21 875 000,0»; |

в)

| | | |
|---|---|---|
| «01 06 08 00 00 0000 000 | Ил эчендә бирелгән башка бюджет кредитлары (ссудалары) | 20 265 720,0 |
| 01 06 08 00 00 0000 600 | Ил эчендә бирелгән башка бюджет кредитларын (ссудаларын) кире кайтару | 20 265 720,0 |
| 01 06 08 00 02 0000 640 | Ил эчендә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән башка бюджет кредитларын (ссудаларын) кире кайтару | 20 265 720,0» |

юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «01 06 08 00 00 0000 000 | Ил эчендә бирелгән башка бюджет кредитлары (ссудалары) | 29 140 720,0 |
| 01 06 08 00 00 0000 600 | Ил эчендә бирелгән башка бюджет кредитларын (ссудаларын) кире кайтару | 29 140 720,0 |
| 01 06 08 00 02 0000 640 | Ил эчендә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән башка бюджет кредитларын (ссудаларын) кире кайтару | 29 140 720,0»; |

3) 4 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына
Татарстан Республикасы бюджеты турында»
Татарстан Республикасы Законына
4 нче кушымта

## 2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары арасында керемнәр бүлү нормативлары

(процентларда)

| Код | Керемнәр төркемнәре, төркемчәләре, статьялары һәм ярдәмче статьялары исеме | Татарстан Республикасы бюджеты | Җирле бюджетлар | | | | Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр округлары | муниципаль районнар | авыл җирлекләре | шәһәр җирлекләре | |
| 1 05 00000 00 0000 110 | Җыелма керемгә салымнар | | | | | | |
| 1 05 03020 01 0000 110 | Бердәй авыл хуҗалыгы салымы (2011 елның 1 гыйнварына кадәр тәмамланган салым чорлары өчен) | | 90 | 60 | 30 | 30 | |
| 1 09 00000 00 0000 000 | Бетерелгән салымнар, җыемнар һәм бүтән мәҗбүри түләүләр буенча бурыч һәм яңадан исәпләүләр | | | | | | |
| 1 09 04010 02 0000 110 | Предприятиеләр мөлкәтенә салым | 100 | | | | | |
| 1 09 06010 02 0000 110 | Сатулардан салым | 100 | | | | | |
| 1 09 06020 02 0000 110 | Мәгариф учреждениеләре ихтыяҗларына юридик затлардан алына торган җыем | 100 | | | | | |
| 1 09 06030 02 0000 110 | Башка салымнар һәм җыемнар <*> | 100 | | | | | |
| 1 09 07012 04 0000 110 | Шәһәр округлары территорияләрендә туплана торган реклама салымы | | 100 | | | | |
| 1 09 07013 05 0000 110 | Муниципаль районнар территорияләрендә туплана торган реклама салымы | | | 100 | | | |
| 1 09 07032 04 0000 110 | Гражданнардан һәм предприятиеләрдән, учреждениеләрдән, оешмалардан милициягә тотуга, территорияләрне төзекләндерүгә, мәгариф ихтыяҗларына һәм башка максатларга шәһәр округлары территорияләрендә туплана торган максатчан җыемнар | | 100 | | | | |
| 1 09 07033 05 0000 110 | Гражданнардан һәм предприятиеләрдән, учреждениеләрдән, оешмалардан милициягә тотуга, территорияләрне төзекләндерүгә, мәгариф ихтыяҗларына һәм башка максатларга муниципаль районнар территорияләрендә туплана торган максатчан җыемнар | | | 100 | | | |
| 1 09 07052 04 0000 110 | Шәһәр округлары территорияләрендә туплана торган башка җирле салымнар һәм җыемнар | | 100 | | | | |
| 1 09 07053 05 0000 110 | Муниципаль районнар территорияләрендә туплана торган башка җирле салымнар һәм җыемнар | | | 100 | | | |

| Код | Керемнәр төркемнәре, төркемчәләре, статьялары һәм ярдәмче статьялары исеме | Татарстан Республикасы бюджеты | Җирле бюджетлар | | | | Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр округлары | муниципаль районнар | авыл җирлекләре | шәһәр җирлекләре | |
| 1 09 11010 02 0000 110 | Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллануга бәйле патент хакы рәвешендә алына торган салым | | 100 | 100 | | | |
| 1 09 11020 02 0000 110 | Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллануга бәйле патент хакы рәвешендә алына торган салымнар (2011 елның 1 гыйнварына кадәр тәмамланган салым чорлары өчен) | | 90 | 90 | | | |
| 1 11 00000 00 0000 000 | Дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге мөлкәттән файдаланудан керемнәр | | | | | | |
| 1 11 05026 04 0000 120 | Федераль милектә булган һәм идарә итү, эш йөртү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган, шәһәр округлары чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре өчен аренда түләве рәвешендә алына торган керемнәр, шулай ук күрсәтелгән җир кишәрлекләренә аренда шартнамәләрен төзү хокукын сатудан акчалар | 50 | 50 | | | | |



| Код | Керемнәр төркемнәре, төркемчәләре, статьялары һәм ярдәмче статьялары исеме | Татарстан Республикасы бюджеты | Җирле бюджетлар | | | | Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр округлары | муниципаль районнар | авыл җирлекләре | шәһәр җирлекләре | |
| 1 11 05026 05 0000 120 | Федераль милектә булган һәм идарә итү, эш йөртү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган, муниципаль районнарның җирлекара территорияләре чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре өчен аренда түләве рәвешендә алына торган керемнәр, шулай ук күрсәтелгән җир кишәрлекләренә аренда шартнамәләрен төзү хокукын сатудан акчалар | 50 | | 50 | | | |
| 1 11 05026 10 0000 120 | Федераль милектә булган һәм идарә итү, эш йөртү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган, авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре өчен аренда түләве рәвешендә алына торган керемнәр, шулай ук күрсәтелгән җир кишәрлекләренә аренда шартнамәләрен төзү хокукын сатудан акчалар | 50 | | | 50 | | |

| Код | Керемнәр төркемнәре, төркемчәләре, статьялары һәм ярдәмче статьялары исеме | Татарстан Республикасы бюджеты | Җирле бюджетлар | | | | Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр округлары | муниципаль районнар | авыл җирлекләре | шәһәр җирлекләре | |
| 1 11 05026 13 0000 120 | Федераль милектә булган һәм идарә итү, эш йөртү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган, шәһәр җирлекләре чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре өчен аренда түләве рәвешендә алына торган керемнәр, шулай ук күрсәтелгән җир кишәрлекләренә аренда шартнамәләрен төзү хокукын сатудан акчалар | 50 | | | | 50 | |
| 1 13 00000 00 0000 000 | Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән (эшләр башкарудан) һәм дәүләт чыгымнарын компенсацияләүдән керемнәр | | | | | | |
| 1 13 01994 04 0000 130 | Шәһәр округлары бюджетлары акчаларын алучыларның түләүле хезмәт күрсәтүләреннән (эшләреннән) бүтән керемнәр | | 100 | | | | |
| 1 13 01995 05 0000 130 | Муниципаль районнар бюджетлары акчаларын алучыларның түләүле хезмәт күрсәтүләреннән (эшләреннән) бүтән керемнәр | | | 100 | | | |
| 1 13 01995 10 0000 130 | Авыл җирлекләре бюджетлары акчаларын алучыларның түләүле хезмәт күрсәтүләреннән (эшләреннән) бүтән керемнәр | | | | 100 | | |
| 1 13 01995 13 0000 130 | Шәһәр округлары бюджетлары акчаларын алучыларның түләүле хезмәт күрсәтүләреннән (эшләреннән) бүтән керемнәр | | | | | 100 | |
| 1 13 02064 04 0000 130 | Шәһәр округлары мөлкәтен эксплуатацияләүгә бәйле тотылган чыгымнарны каплау рәвешендә керә торган керемнәр | | 100 | | | | |
| 1 13 02065 05 0000 130 | Муниципаль районнар мөлкәтен эксплуатацияләүгә бәйле тотылган чыгымнарны каплау рәвешендә керә торган керемнәр | | | 100 | | | |
| 1 13 02065 10 0000 130 | Авыл җирлекләре мөлкәтен эксплуатацияләүгә бәйле тотылган чыгымнарны каплау рәвешендә керә торган керемнәр | | | | 100 | | |
| 1 13 02065 13 0000 130 | Шәһәр җирлекләре бюджетлары акчаларын алучыларның түләүле хезмәт күрсәтүләреннән (эшләреннән) башка керемнәр | | | | | 100 | |

| Код | Керемнәр төркемнәре, төркемчәләре, статьялары һәм ярдәмче статьялары исеме | Татарстан Республикасы бюджеты | Җирле бюджетлар | | | | Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр округлары | муниципаль районнар | авыл җирлекләре | шәһәр җирлекләре | |
| 1 13 02992 02 0001 130 | Үткән еллардагы дебитор бурычны кире кайтарудан Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын компенсацияләүдән бүтән керемнәр | 100 | | | | | |
| 1 13 02992 02 0002 130 | Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын компенсацияләүдән бүтән керемнәр | 100 | | | | | |
| 1 13 02994 04 0000 130 | Шәһәр округлары бюджетлары чыгымнарын компенсацияләүдән бүтән керемнәр | | 100 | | | | |
| 1 13 02995 05 0000 130 | Муниципаль районнар бюджетлары чыгымнарын компенсацияләүдән бүтән керемнәр | | | 100 | | | |
| 1 13 02995 10 0000 130 | Авыл җирлекләре бюджетлары чыгымнарын компенсацияләүдән бүтән керемнәр | | | | 100 | | |
| 1 13 02995 13 0000 130 | Шәһәр җирлекләре бюджетлары чыгымнарын компенсацияләүдән бүтән керемнәр | | | | | 100 | |
| 1 14 00000 00 0000 000 | Матди һәм матди булмаган активларны сатудан керемнәр | | | | | | |



| Код | Керемнәр төркемнәре, төркемчәләре, статьялары һәм ярдәмче статьялары исеме | Татарстан Республикасы бюджеты | Җирле бюджетлар | | | | Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр округлары | муниципаль районнар | авыл җирлекләре | шәһәр җирлекләре | |
| 1 14 06032 04 0000 430 | Федераль милектә булган һәм идарә итү, эш йөртү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган, шәһәр округлары чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен сатудан керемнәр | 50 | 50 | | | | |
| 1 14 06033 05 0000 430 | Федераль милектә булган һәм идарә итү, эш йөртү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган, муниципаль районнарның җирлекара территорияләре чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен сатудан керемнәр | 50 | | 50 | | | |
| 1 14 06033 10 0000 430 | Федераль милектә булган һәм идарә итү, эш йөртү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган, авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен сатудан керемнәр | 50 | | | 50 | | |

| Код | Керемнәр төркемнәре, төркемчәләре, статьялары һәм ярдәмче статьялары исеме | Татарстан Республикасы бюджеты | Җирле бюджетлар | | | | Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр округлары | муниципаль районнар | авыл җирлекләре | шәһәр җирлекләре | |
| 1 14 06033 13 0000 430 | Федераль милектә булган һәм идарә итү, эш йөртү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган, шәһәр җирлекләре чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен сатудан керемнәр | 50 | | | | 50 | |
| 1 14 07020 04 0000 410 | Федераль милектә булган һәм идарә итү, эш йөртү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган, шәһәр округлары чикләрендә урнашкан күчемсез мөлкәтне мондый күчемсез мөлкәт объектлары биләгән җир кишәрлекләре белән бергә сатудан керемнәр | 50 | 50 | | | | |
| 1 14 07030 05 0000 410 | Федераль милектә булган һәм идарә итү, эш йөртү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган, муниципаль районнарның җирлекара территорияләре чикләрендә урнашкан | 50 | | 50 | | | |



| Код | Керемнәр төркемнәре, төркемчәләре, статьялары һәм ярдәмче статьялары исеме | Татарстан Республикасы бюджеты | Җирле бюджетлар | | | | Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр округлары | муниципаль районнар | авыл җирлекләре | шәһәр җирлекләре | |
| | күчемсез мөлкәтне мондый күчемсез мөлкәт объектлары биләгән җир кишәрлекләре белән бергә сатудан керемнәр | | | | | | |
| 1 14 07030 10 0000 410 | Федераль милектә булган һәм идарә итү, эш йөртү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган, авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан күчемсез мөлкәтне мондый күчемсез мөлкәт объектлары биләгән җир кишәрлекләре белән бергә сатудан керемнәр | 50 | | | 50 | | |
| 1 14 07030 13 0000 410 | Федераль милектә булган һәм идарә итү, эш йөртү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган, шәһәр җирлекләре чикләрендә урнашкан күчемсез мөлкәтне мондый күчемсез мөлкәт объектлары биләгән җир кишәрлекләре белән бергә сатудан керемнәр | 50 | | | | 50 | |
| 1 15 00000 00 0000 000 | Административ түләүләр һәм җыемнар | | | | | | |

| Код | Керемнәр төркемнәре, төркемчәләре, статьялары һәм ярдәмче статьялары исеме | Татарстан Республикасы бюджеты | Җирле бюджетлар | | | | Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр округлары | муниципаль районнар | авыл җирлекләре | шәһәр җирлекләре | |
| 1 15 02040 04 0000 140 | Аерым функцияләрне башкарган өчен шәһәр округларының җирле үзидарә органнары (оешмалары) тарафыннан алына торган түләүләр | | 100 | | | | |
| 1 15 02050 05 0000 140 | Аерым функцияләрне башкарган өчен муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары (оешмалары) тарафыннан алына торган түләүләр | | | 100 | | | |
| 1 15 02050 10 0000 140 | Аерым функцияләрне башкарган өчен авыл җирлекләрнең җирле үзидарә органнары (оешмалары) тарафыннан алына торган түләүләр | | | | 100 | | |
| 1 15 02050 13 0000 140 | Аерым функцияләрне башкарган өчен шәһәр җирлекләрнең җирле үзидарә органнары (оешмалары) тарафыннан алына торган түләүләр | | | | | 100 | |
| 1 16 00000 00 0000 000 | Штрафлар, санкцияләр, зыянны каплау | | | | | | |
| 1 16 90020 02 0001 140 | Акчалата түләтүләрдән (штрафлардан) һәм зыянны каплауның бүтән суммаларыннан Татарстан Республикасы бюджетына кертелә торган бүтән кертемнәр | 100 | | | | | |



| Код | Керемнәр төркемнәре, төркемчәләре, статьялары һәм ярдәмче статьялары исеме | Татарстан Республикасы бюджеты | Җирле бюджетлар | | | | Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр округлары | муниципаль районнар | авыл җирлекләре | шәһәр җирлекләре | |
| 1 16 90020 02 0003 140 | Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар ташуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт контракты шартларын бозган өчен акчалата түләтүләр (неустойка) | 100 | | | | | |
| 1 16 90020 02 0004 140 | Дәүләт заказлары буенча шикаять һәм дәгъва эшләре нәтиҗәсендә акчалата түләтүләр | 100 | | | | | |
| 1 17 00000 00 0000 000 | Салым булмаган башка керемнәр | | | | | | |
| 1 17 01040 04 0000 180 | Шәһәр округлары бюджетларына кертелә торган ачыкланмаган кертемнәр | | 100 | | | | |
| 1 17 01050 05 0000 180 | Муниципаль районнар бюджетларына кертелә торган ачыкланмаган кертемнәр | | | 100 | | | |
| 1 17 01050 10 0000 180 | Авыл җирлекләре бюджетларына кертелә торган ачыкланмаган кертемнәр | | | | 100 | | |
| 1 17 01050 13 0000 180 | Шәһәр җирлекләре бюджетларына кертелә торган ачыкланмаган кертемнәр | | | | | 100 | |
| 1 17 01090 09 0000 180 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына кертелә торган ачыкланмаган кертемнәр | | | | | | 100 |

| Код | Керемнәр төркемнәре, төркемчәләре, статьялары һәм ярдәмче статьялары исеме | Татарстан Республикасы бюджеты | Җирле бюджетлар: шәһәр округлары | Җирле бюджетлар: муниципаль районнар | Җирле бюджетлар: авыл җирлекләре | Җирле бюджетлар: шәһәр җирлекләре | Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 17 02010 04 0000 180 | Шәһәр округлары территорияләрендә урнашкан авыл хуҗалыгы җирләрен тартып алуга бәйле рәвештә авыл хуҗалыгы җитештерүе югалтуларын каплау (2008 елның 1 гыйнварына кадәр барлыкка килгән йөкләмәләр буенча) | | 100 | | | | |
| 1 17 02020 05 0000 180 | Җирлекара территорияләрдә урнашкан авыл хуҗалыгы җирләрен тартып алуга бәйле рәвештә авыл хуҗалыгы җитештерүе югалтуларын каплау (2008 елның 1 гыйнварына кадәр барлыкка килгән йөкләмәләр буенча) | | | 100 | | | |
| 1 17 02020 10 0000 180 | Авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан авыл хуҗалыгы җирләрен тартып алуга бәйле рәвештә авыл хуҗалыгы җитештерүе югалтуларын каплау (2008 елның 1 гыйнварына кадәр барлыкка килгән йөкләмәләр буенча) | | | | 100 | | |



| Код | Керемнәр төркемнәре, төркемчәләре, статьялары һәм ярдәмче статьялары исеме | Татарстан Республикасы бюджеты | Җирле бюджетлар: шәһәр округлары | Җирле бюджетлар: муниципаль районнар | Җирле бюджетлар: авыл җирлекләре | Җирле бюджетлар: шәһәр җирлекләре | Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 17 02020 13 0000 180 | Шәһәр җирлекләре территорияләрендә урнашкан авыл хуҗалыгы җирләрен тартып алуга бәйле рәвештә авыл хуҗалыгы җитештерүе югалтуларын каплау (2008 елның 1 гыйнварына кадәр барлыкка килгән йөкләмәләр буенча) | | | | | 100 | |
| 1 17 05020 02 0001 180 | Татарстан Республикасы бюджетының салым булмаган башка керемнәре | 100 | | | | | |
| 1 17 05020 02 0002 180 | Гражданнарга дәүләт пенсияләренә Татарстан Республикасы алдындагы аерым казанышлар өчен өстәмә түләүгә оешмалардан кертемнәр | 100 | | | | | |
| 1 17 05040 04 0000 180 | Шәһәр округлары бюджетларыннан салым булмаган башка керемнәр | | 100 | | | | |
| 1 17 05050 05 0000 180 | Муниципаль районнар бюджетларыннан салым булмаган башка керемнәр | | | 100 | | | |
| 1 17 05050 10 0000 180 | Авыл җирлекләре бюджетларыннан салым булмаган башка керемнәр | | | | 100 | | |
| 1 17 05050 13 0000 180 | Шәһәр җирлекләре бюджетларыннан салым булмаган башка керемнәр | | | | | 100 | |
| 1 17 14020 04 0000 180 | Шәһәр округлары бюджетларына гражданнарның үзләре күчерә торган салым акчалары | | 100 | | | | |

| Код | Керемнәр төркемнәре, төркемчәләре, статьялары һәм ярдәмче статьялары исеме | Татарстан Республикасы бюджеты | Җирле бюджетлар | | | | Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр округлары | муниципаль районнар | авыл җирлекләре | шәһәр җирлекләре | |
| 1 17 14030 05 0000 180 | Муниципаль районнар бюджетларына гражданнарның үзләре күчерә торган салым акчалары | | | 100 | | | |
| 1 17 14030 10 0000 180 | Авыл җирлекләре бюджетларына гражданнарның үзләре күчерә торган салым акчалары | | | | 100 | | |
| 1 17 14030 13 0000 180 | Шәһәр җирлекләре бюджетларына гражданнарның үзләре күчерә торган салым акчалары | | | | | 100 | |

-------------------------------

<*> – бетерелгән региональ салымнар һәм җыемнар өлешендә»;

4) 6 нчы кушымтада:

а)

«719 Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы»

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

«719 1 08 07340 01 0000 110 Региональ спорт федерациясенә дәүләт аккредитациясе бирү турында таныклык биргән өчен дәүләт пошлинасы»;

б)

«720 1 11 05022 02 0000 120 Россия Федерациясе субъектлары милкендәге җирләр (Россия Федерациясе субъектлары бюджет һәм автоном учреждениеләренең җир кишәрлекләреннән тыш) өчен аренда түләве рәвешендә алына торган керемнәр, шулай ук әлеге җирләр өчен аренда шартнамәләре төзүгә хокукны сатудан акчалар»



юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

«720 1 11 05026 04 0000 120 Федераль милектә булган һәм идарә итү, эш йөртү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган, шәһәр округлары чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре өчен аренда түләве рәвешендә алына торган керемнәр, шулай ук күрсәтелгән җир кишәрлекләренә аренда шартнамәләрен төзү хокукын сатудан акчалар

720 1 11 05026 05 0000 120 Федераль милектә булган һәм идарә итү, эш йөртү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган, муниципаль районнарның җирлекара территорияләре чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре өчен аренда түләве рәвешендә алына торган керемнәр, шулай ук күрсәтелгән җир кишәрлекләренә аренда шартнамәләрен төзү хокукын сатудан акчалар

720 1 11 05026 10 0000 120 Федераль милектә булган һәм идарә итү, эш йөртү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган, авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре өчен аренда түләве рәвешендә алына торган керемнәр, шулай ук күрсәтелгән җир кишәрлекләренә аренда шартнамәләрен төзү хокукын сатудан акчалар

720 1 11 05026 13 0000 120 Федераль милектә булган һәм идарә итү, эш йөртү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган, шәһәр җирлекләре чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре өчен аренда түләве рәвешендә алына торган керемнәр, шулай ук күрсәтелгән җир кишәрлекләренә аренда шартнамәләрен төзү хокукын сатудан акчалар»;

в)

«720 1 14 06022 02 0000 430 Россия Федерациясе субъектлары милкендәге җир кишәрлекләрен (Россия Федерациясе субъектлары бюджет һәм автоном учреждениеләренең җир кишәрлекләреннән тыш) сатудан керемнәр»

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

«720 1 14 06032 04 0000 430 Федераль милектә булган һәм идарә итү, эш йөртү вәкаләтләре Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган, шәһәр округлары чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен сатудан керемнәр

720 1 14 06033 05 0000 430 Федераль милектә булган һәм идарә итү, эш йөртү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган, муниципаль районнарның җирлекара территорияләре чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен сатудан керемнәр

| | | |
|---|---|---|
| 720 | 1 14 06033 10 0000 430 | Федераль милектә булган һәм идарә итү, эш йөртү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган, авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен сатудан керемнәр |
| 720 | 1 14 06033 13 0000 430 | Федераль милектә булган һәм идарә итү, эш йөртү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган, шәһәр җирлекләре чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен сатудан керемнәр |
| 720 | 1 14 07020 04 0000 410 | Федераль милектә булган һәм идарә итү, эш йөртү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган, шәһәр округлары чикләрендә урнашкан күчемсез мөлкәтне мондый күчемсез мөлкәт объектлары биләгән җир кишәрлекләре белән бергә сатудан керемнәр |
| 720 | 1 14 07030 05 0000 410 | Федераль милектә булган һәм идарә итү, эш йөртү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган, муниципаль районнарның җирлекара территорияләре чикләрендә урнашкан күчемсез мөлкәтне мондый күчемсез мөлкәт объектлары биләгән җир кишәрлекләре белән бергә сатудан керемнәр |
| 720 | 1 14 07030 10 0000 410 | Федераль милектә булган һәм идарә итү, эш йөртү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган, авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан күчемсез мөлкәтне мондый күчемсез мөлкәт объектлары биләгән җир кишәрлекләре белән бергә сатудан керемнәр |
| 720 | 1 14 07030 13 0000 410 | Федераль милектә булган һәм идарә итү, эш йөртү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган, шәһәр җирлекләре чикләрендә урнашкан күчемсез мөлкәтне мондый күчемсез мөлкәт объектлары биләгән җир кишәрлекләре белән бергә сатудан керемнәр»; |

г)

| | | |
|---|---|---|
| «781 | 1 08 07142 01 0000 110 | Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнары тарафыннан тракторларга, үзйөрешле юл-төзелеш һәм башка үзйөрешле машиналарга һәм аларның прицепларына дәүләт техник күзәтүе уздыру турында документлар бирүгә, мототранспорт чараларына, прицепларга, тракторларга, үзйөрешле юл-төзелеш һәм башка үзйөрешле машиналарга дәүләт теркәве уздыруга, тракторчы-машинист (тракторчы) таныклыклары, үзйөрешле машиналар белән идарә итү хокукына вакытлыча, шул исәптән югалганнары яисә куллана алмаслык хәлгә килгәннәре урынына, таныклык бирүгә бәйле гамәлләр кылган өчен дәүләт пошлинасы» |



юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «781 | 1 08 07160 01 0000 110 | Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнары уку-укыту учреждениеләренә тиешле органнар тарафыннан аккредитация бирү турындагы мәсьәләне карау һәм күрсәтелгән учреждениеләргә тракторчылар, үзйөрешле машиналар машинистлары әзерләү хокукына лицензия бирү өчен җиһазларның һәм уку-укыту барышын тәэмин итүнең таләпләргә туры килүе турында белем таныклыклары биргән өчен дәүләт пошлинасы». |

## 2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 20 феврале
№ 6-ТРЗ

# II
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҺӘМ АНЫҢ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 7. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2015 елның язгы сессиясе секретариаты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2015 елның язгы сессиясе секретариатын түбәндәге Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары составында сайларга:

Секретариат җитәкчесе:

Касыймов Илдус Әсгать улы

Секретариат әгъзалары:

Галәвев Әсфән Галләм улы
Демидов Алексей Алексеевич
Кузьмичева Елена Ивановна
Сөләйманов Рифнур Хәйдәр улы.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 376-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 8. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2015 елның язгы сессиясе регламент төркеме турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2015 елның язгы сессиясе регламент төркемен түбәндәге Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары составында сайларга:

Төркем җитәкчесе:

Власов Валерий Александрович

Төркем әгъзалары:

Рачков Сергей Геннадьевич
Садриев Камил Гайнетдин улы.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 377-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 9. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2015 елның язгы сессиясе электрон системадан файдаланып тавыш бирүне тикшереп тору комиссиясе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2015 елның язгы сессиясе электрон системадан файдаланып тавыш бирүне тикшереп тору комиссиясен түбәндәге Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары составында сайларга:

Комиссия җитәкчесе:

Исаева Анастасия Георгиевна

Комиссия әгъзалары:

Комисаров Александр Владимирович
Махеев Вадим Евгеньевич.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 378-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 10. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2015 елның язгы сессиясе редакция комиссиясе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**
Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2015 елның язгы сессиясе редакция комиссиясен түбәндәге Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары составында сайларга:

Редакция комиссиясе җитәкчесе:

Гыйниятов Хәлил Зиннур улы

Редакция комиссиясе әгъзалары:

Бакова Ирина Николаевна
Миңнеголов Фәрит Герт улы
Рәхимов Марат Муллаәхмәт улы
Салихов Ирек Фәрит улы.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 379-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 11. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының бишенче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**
Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы бишенче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 77-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
3. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 38-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
4. «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында һәм «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 40-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
5. «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 5 һәм $6^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 41-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
6. «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» Федераль законның $16^6$ һәм $16^{6-1}$ статьяларын гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» 39-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

7. «Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында» 49-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

8. «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 31-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

9. «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 45-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

10. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 36-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

11. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 76-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

12. «Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 78-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

13. «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 75-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

14. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү һәм «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законындагы 2 статьяның үз көчен югалтуын тану хакында» 71-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

15. «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 12 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 85-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).



16. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 79-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

17. «Татарстан Республикасында җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыруга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 30-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

18. 2014 елда полиция эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министры хисабы.

19. «2014 елда Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен саклау турында» Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил доклады.

20. Татарстан Республикасы Хисап палатасына йөкләмә турында.

21. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 28 һәм 87 статьяларына үзгәрешләр кертү турында.

22. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 683952-6 номерлы федераль закон проекты турында (шәхси белешмәләр хакындагы законнарны бозган өчен җаваплылык билгели торган нигезләмәләрне төгәлләштерү өлешендә).

23. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренә мәгълүмат бирмәгән өчен җаваплылык билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 676544-6 номерлы федераль закон проекты турында.

24. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 6.24 статьясына үзгәреш кертү хакында» 680433-6 номерлы федераль закон проекты турында (балигъ булмаганнар тәмәке тарткан өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә).

25. «Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр турында» Федераль законга һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 659325-6 номерлы федераль закон проекты турында (наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр сатуны һәм аларны законсыз кулланууны кисәтүгә юнәлдерелгән чараларны камилләштерү хакында).

26. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына һәм Россия Федерациясенең башка закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 690757-6 номерлы федераль закон проекты турында (җитештерү һәм куллану калдыкла-

ры белән эш итү өлкәсендә административ хокук бозулар составын төгәлләштерү хакында).

27. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына алкоголь һәм спиртлы продукцияне җитештерү һәм аларның әйләнеше өлкәсендәге хокук бозулар өчен административ җаваплылыкны көчәйтү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 676596-6 номерлы федераль закон проекты турында.

28. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 681710-6 номерлы федераль закон проекты турында (террорчылык эшчәнлеген һәм (яисә) экстремистлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга гавами чакырулар булган йә мондый эшчәнлекне башкару кирәклеген нигезли яисә аклый торган массакүләм мәгълүмат чарасы продукциясен, шулай ук көч куллануны һәм рәхимсезлекне пропагандалый торган материаллары булган массакүләм мәгълүмат чарасы продукциясен җитештерү һәм чыгару өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә).

29. «Россия Федерациясе гражданнарының Россия Федерациясе эчендә күчеп йөрү ирекге, булу һәм яшәү урынын сайлап алу хокукы турында» Россия Федерациясе Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Пенза өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

30. «Россия Федерациясе Җинаять кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Төньяк Осетия – Алания Республикасы Парламентының закон чыгару инициативасы хакында.

31. «Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 685107-6 номерлы федераль закон проекты хакында («капиталь ремонт чыгымнары» төшенчәсен төгәлләштерү һәм банк исәпләгән процентлар тотылачак юнәлешне билгеләү өлешендә).

32. «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» Федераль законның 14[1] статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 667710-6 номерлы федераль закон проекты турында (14[1] статья терминологиясен «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне, аларның әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү турында).



33. «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 679165-6 номерлы федераль закон проекты турында («Хезмәткә һәм оборонага әзер» Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын гамәлгә кертү өлешендә).

34. «Балалары булган гаиләләргә дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Амур өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

35. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 649573-6 номерлы федераль закон проекты турында (белем алучыларны практик яктан әзерләү өчен медицина оешмалары мөлкәтеннән файдалану нигезләрен төгәлләштерү хакында).

36. «Россия Федерациясе Музейлар фонды һәм Россия Федерациясендә музейлар турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 692856-6 номерлы федераль закон проекты турында.

37. «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 682349-6 номерлы федераль закон проекты турында (тарихи җирлек чикләрендә эшчәнлекне җайга салуны камилләштерү өлешендә).

38. «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) турында» 682357-6 номерлы федераль закон проекты турында (мәдәни мирас объектларын саклау зоналарын билгеләүнең гадиләштерелгән механизмнарын кертү өлешендә).

39. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 85 статьясына үзгәреш кертү хакында» 687920-6 номерлы федераль закон проекты турында (муниципаль берәмлекләрнең чикләрен шәһәр төзелеше һәм җир законнары таләпләре нигезендә тасвирлау һәм раслау срогын озайту өлешендә).

40. «Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында (Россия Федерациясе дәүләт хезмәте төрләрен төгәлләштерү өлешендә)» 685589-6 номерлы федераль закон проекты турында.

41. «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законның 16 статьясына һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 685728-6 номерлы федераль закон проекты турында (дәүләт граждан хезмәтенә һәм муниципаль хезмәткә кабул иткәндә куела торган чикләүләр исемлеген киңәйтү өлешендә).

42. «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законның 48 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 690771-6 номерлы федераль закон проекты турында (вакытлы контракт шартларында «җитәкчеләр» категориясе вазыйфасын биләүче дәүләт граждан хезмәткәрләренә яллаучы вәкиленең тәкъдиме белән аттестация үткәрү өлешендә).

43. «Россия Федерациясе Дәүләт флагы турында» Федераль конституциячел законның 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль конституциячел закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Амур өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

44. «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәреш кертү турында» 674079-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисенең чираттагы финанс елына һәм план чорына федераль бюджет турында закон проектын һәм аның үтәлеше хакындагы хисапны Дәүләт Думасы утырышында тәкъдим итү процедурасын беркетү өлешендә).

45. «Россия Федерациясе Салым кодексының 396 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 686306-6 номерлы федераль закон проекты хакында (күчемсез мөлкәт объектларына хокукны дәүләт теркәвен һәм дәүләт кадастр исәбенә куюны үз вакытында үткәрүне кызыксындыру өлешендә).

46. «Россия Федерациясе Салым кодексына салым администрацияләвен камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 688389-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

47. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 220 статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы хакында.

48. «Россия Федерациясе Җир кодексының 90 статьясына үзгәреш кертү турында» 352800-6 номерлы федераль закон проекты хакында (тимер юл транспорты эшчәнлеген тәэмин итә торган ягулык, башка куркыныч матдәләр һәм материаллар саклау объектларын урнаштыру турында).



49. «Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү турында» Федераль законның 21 һәм 27 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 670780-6 номерлы федераль закон проекты турында (аерым категориядәге абонентлар өчен су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү өлкәсендә хокукый җайга салу үзенчәлекләрен билгеләү өлешендә).

50. «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 9 һәм $13^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 676338-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе континенталь шельфы җир асты байлыклары кишәрлекләреннән, шулай ук Россия Федерациясе территориясендә урнашкан һәм аның континенталь шельфы янындагы федераль әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән потенциаль файдаланучыларның субъект составын киңәйтү өлешендә).

51. «Балыкчылык һәм су биологик ресурсларын саклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 681497-6 номерлы федераль закон проекты турында (уылдык чәчү өчен күчү юлларында балыкларның анадром төрләрен саклау таләпләрен билгеләү өлешендә).

52. «Пестицидлар һәм агрохимикатлар белән хәвефсез эш итү турында» Федераль законның 15 статьясына үзгәреш кертү хакында» 683344-6 номерлы федераль закон проекты турында (пестицидлар һәм агрохимикатлар белән хәвефсез эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру өлешендә).

53. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына Россия Федерациясе дәүләт чиге аша чыгару пунктларында дәүләт контроленең төрле рәвешләрен гамәлгә ашыру буенча федераль башкарма хакимият органнарының компетенциясен билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 684157-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

54. «Монополиягә каршы торуны җайга салу һәм азыктөлек куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 704631-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

55. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (Гомуми өлеш)» 703192-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

56. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 697911-6 номерлы федераль закон проекты турында (мәгариф оешмаларында һәм күңел ачу, ял итү оешмаларында утлы ату коралын йөрткән өчен административ җаваплылык билгеләү хакында).

57. «Коррупциягә каршы тору турында» 700152-6 номерлы федераль закон проекты турында (дәүләт һәм муниципаль оешмаларда коррупциягә каршы тору чараларын көчәйтү өлешендә).

58. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәреш кертү хакында» 697564-6 номерлы федераль закон проекты турында (статьяның аерым нигезләмәләрен төгәлләштерү хакында).

59. «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 7[1] статьясына һәм «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, аларда акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» Федераль законның 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 669491-6 номерлы федераль закон проекты турында (күрсәтелгән федераль законнар белән чикләүләр билгеләнгән вазыйфаи затлар исемлеген арттыру хакында).

60. «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның 12[1] статьясына үзгәреш кертү хакында» 675571-6 номерлы федераль закон проекты турында.

61. «Россия Федерациясе Дәүләт гимны турында» Федераль конституциячел законның 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 676711-6 номерлы федераль конституциячел закон проекты турында.

62. «Аерым закон актларына сайлаучылар хокуклары гарантияләрен көчәйтү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 682310-6 номерлы федераль закон проекты турында.

63. Кондратьев Андрей Станиславовичның Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында.

64. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты составындагы үзгәреш турында.

65. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт программаларын гамәлгә ашыруны тикшереп тору комиссиясе составындагы үзгәреш турында.

66. Төрлесеннән.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 380-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 12. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы итеп биш елга Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет суд районы буенча:

5 нче суд участогына – Кәлимуллин Илнар Ирек улын сайларга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 381-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 13. «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 77-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 77-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 382-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 14. «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (77-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (77-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 383-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 15. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 38-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 38-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 384-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 16. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (38-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (38-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

3. Җирле үзидарә органнарына күрсәтелгән законны гамәлгә ашырудан кергән керемнәрне бары тик тиешле

территорияләрдәге халыкны транспорт белән тәэмин итүне яхшырту максатларына җибәрергә тәкъдим итәргә.

4. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетына күрсәтелгән законны караганда гражданнарның аерым категорияләренә парковка урыннары өчен түләү буенча һәм транспорт чараларын түләүле парковка урыннарында эш сәгатьләреннән тыш вакытта (төнге вакытта, эш көне булмаган бәйрәм һәм ял көннәрендә) урнаштырганда ташламалар бирүгә кагылышлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тәкъдимнәрен исәпкә алуны тәкъдим итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 385-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 17. «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 40-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 40-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 386-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 18. «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы законы хакында (40-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы законын (40-5 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 387-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 19. «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 41-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 41-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.
2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты күрсәтелгән закон проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына өченче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 388-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 20. «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» Федераль законның $16^{6}$ һәм $16^{6\text{-}1}$ статьяларын гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» 39-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» Федераль законның $16^{6}$ һәм $16^{6\text{-}1}$ статьяларын гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» 39-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 389-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 21. «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» Федераль законның $16^{6}$ һәм $16^{6\text{-}1}$ статьяларын гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы хакында (39-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» Федераль законның $16^{6}$ һәм $16^{6\text{-}1}$ статьяларын гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын (39-5 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 390-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 22. «Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында» 49-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында» 49-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 391-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 23. «Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында» Татарстан Республикасы законы хакында (49-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында» Татарстан Республикасы законын (49-5 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 392-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 24. «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 31-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 31-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 393-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 25. «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы законы хакында (31-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы законын (31-5 номерлы проект) кабул итәргә.



2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 394-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 26. «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 45-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 45-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты күрсәтелгән закон проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына өченче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 395-V ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 27. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 36-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 36-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 396-V ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 28. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы хакында (36-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын (36-5 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 397-V ДС



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 29. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 76-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 76-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2015 елның 20 мартына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына кертелә дип билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2015 елның 20 апреленә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 398-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 30. «Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 78-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 78-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 399-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 31. «Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (78-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (78-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 400-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 32. «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 75-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Р.Т. Борһанов һәм М.Һ. Галиев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 75-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 401-V ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**33. «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (75-5 номерлы проект)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (75-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 402-V ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**34. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү һәм «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законындагы 2 статьяның үз көчен югалтуын тану хакында» 71-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү һәм «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законындагы 2 статьяның үз көчен югалтуын тану хакында» 71-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2015 елның 20 мартына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2015 елның 20 апреленә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 403-V ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**35. «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 12 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 85-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 12 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 85-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 404-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 36. «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 12 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (85-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 12 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (85-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 405-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 37. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 79-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты тарафыннан кертелгән «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 79-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 406-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 38. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (79-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (79-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 407-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 39. «Татарстан Республикасында җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыруга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 30-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Х.Г. Миргалимов, А.В. Прокофьев һәм А.В. Комисаров тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыруга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының

12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 30-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын кире кагырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 408-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 40. 2014 елда полиция эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министры А.В. Хохорин хисабы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

2014 елда полиция эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министры А.В. Хохорин хисабын игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 409-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 41. «2014 елда Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен саклау турында» Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил доклады хакында

«2014 елда Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен саклау турында» Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил докладын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «2014 елда Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен саклау турында» Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил С.Х. Сабурская докладын игътибарга алырга (доклад кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары «2014 елда Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен саклау турында» Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил докладыннан Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыру мәсьәләләрен карарга һәм алар буенча кирәкле чаралар күрергә тиеш.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы министрлыкларына һәм ведомстволарына, муниципаль берәмлекләр башлыкларына «2014 елда Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен саклау турында» Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил докладындагы тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру, шулай ук кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен бозу очракларына юл куелмау буенча гамәлләр комплексын әзерләү чараларын күрүне тәкъдим итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 410-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 42. Татарстан Республикасы Хисап палатасына йөкләмә турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

2015 елның IV кварталында Татарстан Республикасы Хисап палатасына түбәндәгеләрне үткәрүне йөкләргә:

2012 – 2014 елларда һәм 2015 елның узган чорында Татарстан Республикасы торак пунктларының су белән тәэмин итү системаларын капиталь ремонтлауга, реконструкцияләүгә, төзүгә бүлеп бирелгән дәүләт акчаларыннан файдалану нәтиҗәлелеген тикшерүне;

2012 – 2014 елларда һәм 2015 елның узган чорында ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыруга бүлеп бирелгән

Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан файдалану нәтиҗәлелеген тикшерүне.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 411-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 43. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 28 һәм 87 статьяларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына (2010 елның 9 июнендәге 973-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 2 (I өлеш); 2005, № 3 (II өлеш), № 10 (II өлеш), № 12 (V өлеш); 2006, № 1, № 10 (I өлеш); 2007, № 10, № 12 (IV өлеш); 2008, № 11 (IV өлеш); 2010, № 6 (III өлеш); 2011, № 3, № 12; 2013, № 5, № 12 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 6 (III өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 28 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Комитет утырышының, аны уздыру көнен, вакытын, урынын күрсәтеп, көн тәртибе проекты һәм утырышның көн тәртибе мәсьәләләре буенча материаллар Дәүләт Советы Аппаратының җаваплы хезмәткәре тарафыннан Дәүләт Советының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.»;

2) 87 статьяга түбәндәге эчтәлекле 7 өлеш өстәргә:

«7. Җаваплы комитетка алдан карау өчен җибәрелгән закон проекты бер үк вакытта Дәүләт Советы Аппаратының җаваплы хезмәткәре тарафыннан Дәүләт Советының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.».

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 412-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 44. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 683952-6 номерлы федераль закон проекты турында (шәхси белешмәләр хакындагы законнарны бозган өчен җаваплылык билгели торган нигезләмәләрне төгәлләштерү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 683952-6 номерлы федераль закон проектын (шәхси белешмәләр хакындагы законнарны бозган өчен җаваплылык билгели торган нигезләмәләрне төгәлләштерү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 413-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**45. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренә мәгълүмат бирмәгән өчен җаваплылык билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 676544-6 номерлы федераль закон проекты турында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренә мәгълүмат бирмәгән өчен җаваплылык билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 676544-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 414-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**46. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 6.24 статьясына үзгәреш кертү хакында» 680433-6 номерлы федераль закон проекты турында (балигъ булмаганнар тәмәке тарткан өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 6.24 статьясына үзгәреш кертү хакында» 680433-6 номерлы федераль закон проектын (балигъ булмаганнар тәмәке тарткан өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә) хупларга.



2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 415-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**47. «Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр турында» Федераль законга һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 659325-6 номерлы федераль закон проекты турында (наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр сатуны һәм аларны законсыз куллануны кисәтүгә юнәлдерелгән чараларны камилләштерү хакында)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр турында» Федераль законга һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 659325-6 номерлы федераль закон проектын (наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр сатуны һәм аларны законсыз куллануны кисәтүгә юнәлдерелгән чараларны камилләштерү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 416-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**48. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына һәм Россия Федерациясенең башка закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 690757-6 номерлы федераль закон проекты турында (җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә административ хокук бозулар составын төгәлләштерү хакында)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына һәм Россия Федерациясенең башка закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 690757-6 номерлы федераль закон проектын (җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә административ хокук бозулар составын төгәлләштерү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 417-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**49. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына алкоголь һәм спиртлы продукцияне җитештерү һәм аларның әйләнеше өлкәсендәге хокук бозулар өчен административ җаваплылыкны көчәйтү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 676596-6 номерлы федераль закон проекты турында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына алкоголь һәм спиртлы продукцияне җитештерү һәм аларның әйләнеше өлкәсендәге хокук бозулар өчен административ җаваплылыкны көчәйтү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 676596-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 418-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**50. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 681710-6 номерлы федераль закон проекты турында (террорчылык эшчәнлеген һәм (яисә) экстремистлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга гавами чакырулар булган йә мондый эшчәнлекне башкару кирәклеген нигезли яисә аклый торган массакүләм мәгълүмат чарасы продукциясен, шулай ук көч куллануны һәм рәхимсезлекне пропагандалый торган материаллар булган массакүләм мәгълүмат чарасы продукциясен җитештерү һәм чыгару өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 681710-6 номерлы федераль закон проектын (террорчылык эшчәнлеген һәм (яисә) экстремистлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга гавами чакырулар булган йә мондый эшчәнлекне башкару кирәклеген нигезли яисә аклый торган массакүләм мәгълүмат чарасы продукциясен, шулай ук көч куллануны һәм рәхимсезлекне пропагандалый торган материаллар булган массакүләм мәгълүмат чарасы продукциясен җитештерү һәм чыгару өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 419-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 51. «Россия Федерациясе гражданнарының Россия Федерациясе эчендә күчеп йөрү ирегә, булу һәм яшәү урынын сайлап алу хокукы турында» Россия Федерациясе Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Пенза өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясе гражданнарының Россия Федерациясе эчендә күчеп йөрү ирегә, булу һәм яшәү урынын сайлап алу хокукы турында» Россия Федерациясе Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Пенза өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Пенза өлкәсе Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 420-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 52. «Россия Федерациясе Җинаять кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Төньяк Осетия — Алания Республикасы Парламентының закон чыгару инициативасы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясе Җинаять кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Төньяк Осетия — Алания Республикасы Парламентының закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Төньяк Осетия — Алания Республикасы Парламентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 421-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 53. «Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 685107-6 номерлы федераль закон проекты хакында («капиталь ремонт чыгымнары» төшенчәсен төгәлләштерү һәм банк исәпләгән процентлар тотылачак юнәлешне билгеләү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 685107-6 номерлы федераль закон проектын («капиталь ремонт чыгымнары» төшенчәсен төгәлләштерү

һәм банк исәпләгән процентлар тотылачак юнәлешне билгеләү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 422-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 54. «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» Федераль законның 14[1] статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 667710-6 номерлы федераль закон проекты турында (14[1] статья терминологиясен «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне, аларның әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү турында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» Федераль законның 14[1] статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 667710-6 номерлы федераль закон проектын (14[1] статья терминологиясен «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне, аларның әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү турында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 423-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 55. «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 679165-6 номерлы федераль закон проекты турында («Хезмәткә һәм оборонага әзер» Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын гамәлгә кертү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 679165-6 номерлы федераль закон проектын («Хезмәткә һәм оборонага әзер» Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын гамәлгә кертү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 424-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 56. «Балалары булган гаиләләргә дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Амур өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Балалары булган гаиләләргә дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль

Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Амур өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Амур өлкәсе Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 20 феврале
№ 425-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 57. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 649573-6 номерлы федераль закон проекты турында (белем алучыларны практик яктан әзерләү өчен медицина оешмалары мөлкәтеннән файдалану нигезләрен төгәлләштерү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 649573-6 номерлы федераль закон проектын (белем алучыларны практик яктан әзерләү өчен медицина оешмалары мөлкәтеннән файдалану нигезләрен төгәлләштерү хакында) хупларга.

